## ПРОГРАММАНЫ ҮЗЛӘШТЕРҮДӘН КӨТЕЛГӘН НӘТИҖӘЛӘР

Гомуми төп һәм урта белем бирү мәктәбенед 10-11 нче сыйныфларда ана теле предметын өйрәтү тел берәмлекләрен таный, аңлый һәм анализлый белү күнекмәләре белән бергә, сөйләм культурасын үстерүне, төрле типтагы һәм жанрдагы мәгълүматны үзләштерүне, аларны, сөйләм ситуациясенә һәм төренә карап, дөрес, төгәл итеп башкаларга җиткерә алуны, татар теленең әдәби һәм сөйләм әдәбе нормаларын күз алдында тота.

**Шәхси нәтиҗәләр**:

- татар теленең татар халкы өчен төп милли-мәдәни кыйммәт булуын, ана телендә шәхеснең әхлакый, рухи һәм иҗади яктан формалашудагы ролен аңлау;
- туган телгә мәхәббәт һәм аның белән горурлану хисләре тәрбияләү, туган телне саклау һәм үстерү өлкәсендә эшләргә теләк, омтылыш уяту;
- туган телдә аралашу, үз фикереңне һәм хисләреңне төгәл, анык, күпьяклы итеп белдерү өчен кирәкле булган сүзлек составын һәм грамматик, стилистик чараларны белү;
- аралашу төренә һәм ситуациясенә бәйле сөйләмне куллана һәм үзара бәйли белү;
- иптәшләренең сөйләменә игътибар итү, үзеңнең сөйләмеңә күзәтеп бәя бирү, хаталарны төзәтү, бәхәстә катнашу, төрле дәлилләр кулланып, тема буенча фикер алышу.

**Предметны үзләштерү барышында ирешкән нәтиҗәләр:**

- сөйләмиятнең барлык төрләрен (тыңлау, аңлау, уку, язу) үзләштерү: язма һәм сөйләм теленә караган мәгълүматның темасын, төп һәм өстәмә фикерен аңлау; төрле стильгә һәм жанрга караган текстларны дөрес уку һәм аңлау; төрле чыганаклардан мәгълүмат туплый белү; сүзлекләрдән һәм электрон чаралардан дөрес файдалана белү; аерым бер темага караган материалны туплый, анализлый, эшкәртә һәм үзгәртә белү;
- татар теленең төп функцияләрен, татар теленең башка төрки телләр арасында тоткан урынын, телнең мәдәният, җәмгыять белән тыгыз бәйләнешен аңлау;
- туган тел турындагы фәнни белемнәрнең нигезен булдыру, тел катламнарының, ярусларының үзара бәйләнешен һәм мөнәсәбәтен аңлау;
- тел белеменең төп төшенчәләрен үзләштерү, аның тармаклары турында мәгълүмат булдыру; тел һәм сөйләм, сөйләм төрләре, аралашу ситуацияләре; сөйләм теле, функциональ стильләр, матур әдәбият теле; текст һәм аның төрләре; телнең төп берәмлекләре, аларның аермалы билгеләрен, сөйләмдә кулланылу үзенчәлекләрен белү;
- телнең төп стилистик чараларын, телнең әдәби нормаларын, сөйләм әдәбе нормаларын белү, аларны сөйләмдә дөрес кулланырга өйрәнү;
- тел һәм сөйләм берәмлекләрен аера һәм анализлый белү; тел һәм стилистик чараларның кулланылышына бәйле рәвештә сөйләм төрләрен аера һәм чагыштыра белү;
- телнең сәнгати чараларын аеру, аларның эстетик функцияләрен белү.

10-11 нче сыйныфларда татар телен укытуның **предметара нәтиҗәләре**:

- татар теленең башка фәннәрне өйрәнү һәм белем алу чарасы икәнен аңлау;
- татар телен әдәбият белән бәйләп, тел чараларының матур әдәбият әсәрләрендәге тәэсир көчен, сәнгатьлелеген булдыруда ролен ачыклау; чор әдәбиятына хас тел-сурәтләү чараларының үзенчәлекләрен ачу;
- телне әдәбият белән бәйләп, укыган яки тыңлаган әсәрнең эчтәлеген, планын, конспектын, резюмесын логик эзлекле итеп язарга, сөйләргә өйрәтү;
- телне мәдәният белән бәйләп, татар теленең байлыгына һәм матурлыгына хөрмәт, зәвык тәрбияләү;
- татар телен рус теле белән бәйләп, телләр һәм халыклар арасындагы уртак хәзинә – рухи кыйммәтләргә ихтирам, башка милләт вәкилләренә карата түземле–ихтирамлы мөнәсәбәт тәрбияләү; телләрнең үзара бегланыш-мөнәсәбәтләрен, шул мөнәсәбәтләр нәтиҗәсендә уртак төшенчәләр һәм тел берәмлекләре барлыкка килүне аңлату;
- рус һәм чит телләр, әдәбиятлар белән бәйләп, татар теленең милли-мәдәни үзенчәлекләрен өйрәтү, алган белемнәрне төрле тел күренешләрен аңлатуда куллану;
- телне тарих, җәмгыять белеме фәннәре белән бәйләп, дөнья, кешелек җәмгыяте, аның үсеше турында күзаллау формалаштыру, җәмгыять үсешенең телгә турыдан-туры мөнәсәбәте булуын җиткерү;
- татар теле дәресләрендә алган белем һәм күнекмәләрне телнең кеше һәм җәмгыять тормышында тоткан урынын аңларга ярдәм итү; сөйләмне дөрес куллана, бәяли белергә, үз фикереңнең уңай һәм тискәре якларын аңларга, камилләштерергә өйрәтү;
- рухи мәдәниятнең нигезе булган татар теле ярдәмендә рухи кыйммәтләрнең асылын аңлату;
- әдәби әсәрләрнең теле белән эшләгәндә, татар теле – бәйләүче чараларга бик бай тел, шул чаралар системасын, алар белдергән мәгънәләрне нәтиҗәлерәк үзләштерү максатыннан, стиль мөмкинлекләрен дә исәпкә алып, фикерне төгәл бирердәй сүзтезмә һәм җөмләләрне телебез хәзинәсеннән сайлап ала белү.

## ПРОГРАММАНЫҢ ТӨП ЭЧТӘЛЕГЕ

**Сөйләм.**

Тел һәм сөйләм. Сөйләмнең төрләре (сөйләмә, язма, диологик сөйләм, монологик сөйләм). Сөйләм төрләре һәм аларның үзенчәлекләре.

Кулланылышы ягыннан сөйләм төрләре, аларның үзенчәлекләре: көнкүреш аралашу теле, фәнни аралашу теле, иҗтимагый-сәяси аралашу теле, рәсми аралашу теле.

Сөйләм ситуациясе, аның төп компонентлары.

**Сөйләм эшчәнлеге буларак текст.** Сөйләмә һәм язма текстлар. Текстның мәгънәви һәм композицион бөтенлеге. Текстта сүзләр бәйләнеше. Текст структурасы. Текстның композицион, жанр төрлелеге. Текстка анализ ясау. Текст төзү нормаларының сакланышы (логик яктан төзеклеге, бәйләнеше, темага туры килүе, эзлеклелеге һ.б.)

**Телнең кулланылыш ягыннан төрләре**: көнкүреш сөйләм теле, матур әдәбият теле, функциональ стильләр: фәнни стиль, публицистик стиль, рәсми эш кәгазьләре стиле, хәзерге электрон чаралар теле, интернет теле, аларның үзенчәлекләре. Татар милли мәдәнияте кысаларында һәм мәдәниятара аралашуга бәйле сөйләм нормалары. Татар сөйләменең сәнгатьлелеге. Рәсми һәм рәсми булмаган аралашуда милли-мәдәни нормаларны куллана белү. Татар милли мәдәнияте кысаларында һәм мәдәниятара аралашуга бәйле сөйләм нормалары. Телнең орфоэпик һәм интонацион нормаларын саклап, фикерне җиткерү; сөйләм этикеты үрнәкләреннән дөрес файдалану.

**Тел системасы**

**Татар теле турында гомуми мәгълүмат.**

Телнең аралашу чарасы булуы.

Телнең рухи мирас ядкаре булуы. Татар язуы тарихы, рун, уйгыр, гарәп, латин, кирилл язулары турында төшенчә.

Телнең төп функцияләре. Туган телнең һәрбер халык тормышында һәм кешене шәхес итеп формалаштырудагы роле.
Язма әдәби телнең барлыкка килүе. Хәзерге татар (милли) әдәби теле.

Дөньядагы телләр һәм аларны төркемләү. Кардәш һәм кардәш булмаган телләр. Төрки телләр группасы. Татар теленең төрки телләр арасында тоткан урыны. Татарлар яши торган төбәкләр.

Телнең кеше тормышында һәм җәмгыятьтә тоткан урыны. Әдәби тел турында төшенчә. Татар теленең яшәеш формалары: территориаль һәм иҗтимагый диалектлар, гади сөйләм турында гомуми төшенчә.
Тел һәм мәдәниятнең бәйләнеше. Татар теле – татар әдәбиятының теле. Татар теленең тел сурәтләү чаралары һәм аларның сөйләмдә кулланылышы. Атаклы татар тел галимнәре.

**Фонетика һәм орфоэпия**.

Фонетика һәм орфоэпия турында гомуми төшенчә. Аваз. Фонема. Татар һәм рус телләрендә сузык авазлар һәм тартык авазлар.

Татар телендә басым. Интонация белән эшләү.

Әдәби тел нормалары. Орфоэпик нормалар турында төшенчә. Сөйләмнең әйтелеш нормаларына нисбәтле бәяләү.

**Графика**

Графика һәм орфография. Татар алфавиты.
Рун язуы турында төшенчә. Гарәп язуы үрнәкләре белән таныштыру. Латин графикасы. Кириллица. Телнең орфографик нормалары.

**Морфемика (сүз төзелеше) һәм ясалышы**

Сүз төзелеше һәм ясалышы. Сүзнең мәгънәле кисәкләре. Татар телендә сүз ясалыш ысуллары. Сүз төзелешендәге тарихи үзгәрешләр турында гомуми аңлатма. Этимологик анализ турында төшенчә.
Сүз төзелешенең төп сәнгати чаралары.
Сүзләрне сүз ясалышы һәм төзелеше ягыннан анализлау.

**Лексикология һәм фразеология.**

Сүз – телнең төп берәмлеге. Сүзнең лексик мәгънәсе. Төрки-татар сүзләре һәм алынма сүзләр. Татар теленең сүзлек составы. Нейтраль сүзләр һәм стилистик бизәкле сүзләр.

Лексиканың стилистик катламнары. Фразеологизмнарның сөйләмдә кулланылыш үзенчәлекләре. Икетеллелек шартларында татар теленең лексик һәм фразеологик составы арту.

Татар теленең төп лексик нормалары. Лексиканың төп сәнгати чаралары. Лексик анализ ясау.

**Морфология**

Сүз төркемнәренең лексик-грамматик төрләре. Сүз төркемнәренең классификациясе. Сүз төркемнәренең үзара мөнәсәбәте. Телнең төп морфологик нормалары. Морфологиянең төп сәнгати чаралары.
Морфологик анализ ясау.

**Синтаксис**

Синтаксис буенча гомуми мәгълүмат. Сүзтезмә һәм җөмлә. Җөмләдә сүзләр бәйләнеше. Җөмләнең баш һәм иярчен кисәкләре. Гади җөмлә төрләре.

Кушма җөмлә турында төшенчә. Татар һәм рус телләрендә иярченле кушма җөмләнең төзелеше.

Текст синтаксисы турында гомуми төшенчә. Телнең төп синтаксик нормалары. Синтаксисның төп сәнгати чаралары.
Синтаксик анализ ясау.

**Сөйләм культурасы**

Язма тел һәм сөйләмә тел төшенчәләре. Әдәби сөйләмгә куелган таләпләр турында гомуми мәгълүмат. Сөйләмдә лексик чараларның (синонимнар, антонимнар, калькалар, фразеологизмнар, мәкаль һәм әйтемнәр) кулланылыш мөмкинлекләре.

Хәзерге матбугатта һәм электрон чараларда татар теленең кулланылыш үзенчәлекләре турында гомуми мәгълүмат.

**Пунктуация.**

Татар телендә тыныш билгеләре. Пунктуацион норма. Пунктуацион-мәгънәви кисәк.

**Тел һәм мәдәният**

Татар халкының теле, мәдәнияте һәм тарихы арасындагы бәйләнеш. Татар сөйләм әдәбе. Аралашуның төренә бәйле сөйләм әдәбен куллану.

## УКЫТУНЫ МАТДИ-ТЕХНИК ҺӘМ МӘГЪЛҮМАТИ ЯКТАН ТӘЭМИН ИТҮ

Татар телендә гомуми төп һәм урта белем бирү мәктәпләрендә ана теле предметын укытуның матди-техник һәм мәгълүмати нигезенә түбәндәгеләр кирә:

- белем һәм тәрбия бирү өчен барлык шартлар да тудырылган, санитария һәм янгыннан саклану нормаларына туры килгән уку бинасы һәм мәктәп яны территориясе;
- ана теле предметын өйрәнү өчен җитәрлек күләмдә дәреслекләр һәм өстәмә методик ярдәмлекләр белән тәэмин ителгән китапханә;
- электрон китапханә, башка электрон ресурслар, татарча сайтлардан куллану мөмкинлеге булган компьютер классы;
- лингафон кабинеты;
- электрон һәм басма күрсәтмә әсбаплар, дәреслекләр;
- мультимедиа укыту программалары;
- компьютер программалары;
- 10-11 нче сыйныф укучыларының белемнәрен тикшерү программалары;
- төрле типтагы сүзлекләр, энциклопедияләр;
- белешмә материаллар;
- балалар өчен чыгарылган газета һәм журналлар;
- интерактив тикшерү программалары;
- татар сайтлары (belem.ru; tatarile.org.com ).

1. булуын белү.

**10-11 нче сыйныф укучыларының тел осталыкларына һәм күнекмәләренә таләпләр.**

- Милли телнең иҗтимагый тормыштагы әһәмияте, телне саклау- милләтне саклауның төп өлеше икәнен үзләштерү; татар теленең кайсы телләр белән мөнәсәбәткә керүен белү, моның сәбәбен аңлау;
- Татар теле атмасының күп кенә аерым телләрне атавын аңлау;
- Топонимнарның төркичә булуын, Идел-Урал арасында татарларның бик борынгыдан яшәүләре турында белү;
- Хәзерге татар әдәби теленең төп үзенчәлекләрен, сүзлек составы киңәя баруын аңлату, татар әдәби теленең бар яктан да төзек кагыйдәле, камил, мөстәкыйль тел булуын белү

**Укучыларның белем дәрәҗәсенә таләпләр**

1. Телнең төп функциясен белү;
2. Татар әдәби теле тарихын, аның үсеш этапларын татар теленең үзгәреш тенденцияләрен белү;
3."Сөйләм ситуациясе", "әдәби тел", "тел нормасы", "сөйләм культурасы" төшенчәләренең мәгънәләрен аңлау;
4. Мәктәп курсында өйрәнелгән тел тармакларының система тәшкил итүенә төшенү;
5. Тел белеменә караган иң әһәмиятле төшенчәләрне, билгеләмәләрне белү;
6. Татартеленең төрлетармакларыннаналган мәгълүматка таянып, текстка лингвистик анализ ясау;
7. Телдән һәм язмача бирелгән мәгълүматны үзләштерүнең төрле алымнарын файдалану;
8. Тел-сурәтләү чараларының үзенчәлекләрен аңлау һәм аларны дөрес куллану.

**Формалашырга тиешле күнекмәләр**:

1. Тормыш-көнкүреш, иҗтимагый-мәдәни, фәнни-уку, рәсми эш стильләрен, аларга бәйле булган сөйләм этикеты нормаларын үзләштерү һәм аларны гамәли куллану;
2.Татар әдәби теленең нормаларын (орфоэпик, орфографик, лексик, грамматик, пунктуацион) белү һәм аларны телдән һәм язмача сөйләм процессында дөрес файдалану;
3.Тормыш-көнкүреш, фәнни, рәсми текстларны монологик һәм диалогик характерда, төрле жанрда һәм стильдә язу;
4.Тел-сурәтләү чараларын дөрес кулланып, төрле стиль һәм жанрдагы текстларны рус теленнән татар теленә һәм татар теленнән рус теленә тәрҗемә итү.

## УКЫТУ ПРЕДМЕТЫНА ГОМУМИ АҢЛАТМА

Төп мәктәптә ана теле курсы белем бирү процессының предметара һәм аерым предмет эчендә куелган максатларын тормышка ашыруга йөз тота. *Югары культурага ия булган шәхес тәрбияләү принцибы* 10-11 нче сыйныфларның үзәген тәшкил итә. Бүгенге җәмгыятьтә культура түбәнлеге, аралашу нормаларының, әдәби тел кануннарының вакытлы матбугатта, электрон коммуникация чараларында сакланмавын һәм түбән дәрәҗәдә булуын искә алып, татар әдәби теле нормаларына аерым игътибар бирелә. Икетеллелек һәм глобальләштерү шартларында татар теленә башка теллләрдән кергән сүз һәм аерым конструкцияләрнең кулланауын, аларның сөйләм телендә һәм матур әдәбият телендә урынсыз кулланылуын искә алып, программада укучыларда татар әдәби теленә ихтирам тәрбияләү нигез итеп алына.

10-11 нче сыйныфларда укучыларның татар теле курсыннан алган төп белемнәренә нигезләнә һәм аларны системалаштыру, гомумиләштерүгә йөз тота. Югары сыйныфларда тел иҗтимагый күренеш һәм тамгалар системасы буларак өйрәнелә. Татар теленең үсеш этаплары, төрки һәм европа телләре арасындагы урыны, бүгенге җәмгыятьтә телләрнең үзара мөнәсәбәте, керешүе өйрәнелә.

***Коммуникатив компетенция*** җирлегендә сөйләм эшчәнлегенең төрләре камилләштерелә. Укучы аралашу ситуацияләренә бәйле тел һәм сөйләм берәмлекләрен дөрес, төгәл сайлап, иркен куллана, үз фикерен раслый һәм дәлилли. Төрле стиль һәм жанрга караган текстлар төзи, тәкъдим ителгән текстларның тел үсешенең кайсы этабына каравын күзаллый, текстка лингвистик анализ ясый һ.б.

***Лингвистик компетенция*** татар теленең тармаклары буенча үзләштерергә тиешле төп теоретик мәгълүматлар кирә:

1. "Сөйләм ситуациясе", "әдәби тел", "тел нормасы", "сөйләм культурасы" төшенчәләре. Татар халкының язу тарихы, орфографик принциплар, орфоэпия. Татар теленең фонетик, график, орфографик, орфоэпик нормалары.
2. Лексикология фәненең тармаклары. Сүзнең лексик мәгънәсе, аның үсеш-үзгәреше. Татар теленең сүзлек составын төркемләү. Фразеологик әйтелмәләр, аларның лексик мәгънәсе. Төрле типтагы сүзлекләр. Телнең лексик нормалары.
3. Сүз төзелеше һәм сүз ясалышы, татар теленең сүзлек составын баетуда сүз ясалышының роле.
4. Сүз төркемнәре, аларны төркемләү, сүз төркемнәренең үзара мөнәсәбәте. Телнең морфологик нормалары.
5. Синтаксисның төп берәмлекләре, аларның төрләре. Текст һәм аның берәмлекләренең үзара бәйләнеше. Телнең синтаксик нормалары.
6. Язма һәм сөйләмә тел, аларга хас үзенчәлекләр. Тел-сурәтләү чаралары, аларның төрләре. Татар сөйләменең сәнгатьлелеге.

***Этномәдәни компетенция*** җирлегендә телнең мәдәнияттән һәм тарихтан аерылгысыз булуына игътибарны юнәлтү. Тел берәмлекләрендә, аларның мәгънәләрендә миллилек чагылышын күрә белү, төрле телләрдә уртак төшенчәләрнең һәм берәмлекләрнең кулланылыш үзенчәлеген, алар аша дөньяны танып белүдәге уртак һәм аермалы якларны ачу; тел берәмлекләре аша милли дөнья картинасы ачылу үзенчәлекләрен өйрәтү (мәкаль-әйтемнәр, фразеологик берәмлекләр, ономастик лексика, афоризмнар). Татар сөйләм әдәбе нормалары өйрәтү һ.б.

Программаның төп юнәлеше булып X-XI сыйныфларда укучыларның *сөйләмен үстерү һәм интеллектуаль үсешен тәэмин итү* тора. Программада тел турында теоретик мәгълүмат белән бергә, өйрәнелә торган тел берәмлекләрен, грамматик конструкцияләрнең сөйләмдә кулланылыш мөмкинлекләрен аңлатуга махсус игътибар бирелә.

Шулай итеп, татар мәктәбе өчен туган телен укыту программасы эшлекле якын килүгә нигезләнә һәм аны тормышка ашыру өчен кирәкле алшартларны күзаллап төзелә. Укучыларның сөйләм эшчәнлеге үсеше һәм шәхси үсеш-үзгәреше югарыда саналган компетенцияләрдә ачык чагыла: коммуникатив компетенция төркемендә өйрәнелә торган тел материалы аралашу күнекмәләре булдыру максатын күздә тотып бирелә, лингвистик компетенция төркемендә аралашу өчен кирәкле тел материалының төзелеше, структурасы,

эчтәлеге тәкъдим ителә, социомәдәни компетенция төркемендә тел материалы халыкның мәдәниятен һәм тарихын чагылдыра торган билге буларак бирелә.

## Укыту-методик комплекты

МБГБУ “Фома урта гомуми белем мәктәбе”нең 2018-2019 нчы уку елына укыту планы буенча 10-11 нче сыйныфта туган тел дәресләренә атнага 1 сәгать бирелә,10 сыйныфта 35 атна, ел буена 35сәгать,11 сыйныфта 34 атна, 34 сәгать

**Дәреслек:** Зәкиев М.З., Максимов Н.В. Татар теле: татар урта гомуми белем бирү мәктәпләренең 10-11 нче сыйныфлары өчен дәреслек. – Казан: “Мәгариф”, 2008.

**Өстәмә мәгълүмат чыганагы**: Харисова Ч.М. Татар теле. Теория, күнегүләр, тестлар. – Казан: “Мәгариф”, 2006.